ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

03.03.2025 ел №150

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советының 2024 елның 28 июнендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына салымнар һәм җыемнар турында үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 августындагы 259-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. “Җир салымы турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советының 2024 елның 28 июнендәге 127 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: салым түләүчеләр - физик затлар тарафыннан үткән салым чорыннан соң килүче елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, әгәр әлеге пунктта башкасы каралмаган булса, салым түләүчеләр тарафыннан салым түләнергә тиеш.

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Турай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советының финанс-бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге Советы рәисе Г.Б. Куляшова